Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене  авыл җирлегенең  Күл Черкене  авылында гражданнар җыены карары

15 декабрь 2021 ел                                                                                         № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене  авыл җирлегенең  Күл Черкене  авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2022 елда Күл Черкене  авыл җирлегенең  Күл Черкене  авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия   балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1300 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге  җирле  мәсьәләләрне хәл итүгә

- фронталь төягече һәм юл чапкычы булган МТЗ-82.1 тракторы сатып алу, кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге чорда территорияне карап тотуга (ГСМ, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләүгә) юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Күл Черкене  авыл җирлегенең  Күл Черкене  авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Күл Черкене  авыл җирлеге башлыгы _________  М.К. Истиев

Халык җыены секретаре                              _________  И.Ю. Камалтдинова